**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 2 сентябрендәге 3715 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2022 елның 1 июлендәге 2090 номерлы карары белән расланган Себер Тракты, Халитов һәм Академик Арбузов урамнары белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 2 апрелендәге 575 номерлы «Территорияне планлаштыру документларын, җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнарын әзерләү, килештерү, раслау, аларның гамәлдә булу вакытларын озайту, капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәтләр, файдалануга кертүгә рөхсәтләр бирү үзенчәлекләре турында»гы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 27 июлендәге 722 номерлы «2022, 2023 һәм 2024 елларда территорияне планлаштыру проектларын, территорияне ызанлау проектларын раслау һәм, җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрмичә, әлеге проектларга үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында»гы карарына таянып, проектны эшләү 2023 елда башлануын исәпкә алып **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 1 июлендәге 2090 номерлы карары белән расланган Себер Тракты, Халитов һәм Академик Арбузов урамнары белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектына, әлеге карарның кушымтасы нигезендә планлаштыру проектының аерым өлешләрен раслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 2 сентябрендәге
3715 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2022 елның 1 июлендәге 2090 номерлы карары белән расланган**
**Себер Тракты, Халитов һәм Академик Арбузов урамнары белән**
**чикләнгән территорияне планлаштыру проектына**
**кертелә торган үзгәрешләр**

1. Территорияне план буенча үстерүнең характеристикалары турындагы нигезләмәдә:

1.1. «халыкның планлаштырылган саны – 8 400 кеше» сүзләрен «халыкның планлаштырылган саны – 7 706 кеше» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. «М-1 микрорайоны халкының тыгызлыгы – 351,5 кеше/га» сүзләрен «М-1 микрорайоны халкының тыгызлыгы – 362,2 кеше/га» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 1.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.2 таблица

**Күпкатлы торак төзелешен план буенча урнаштыру зонасы өчен исәпләнгән күрсәткечләр**

| **Күпкатлы торак төзелеше объектлары характеристикалары** | **Планлаштыру структурасы элементы (квартал) чикләрендә билгеләнеше** | | |
|---|---|---|---|
| | **К-1** | **К-2** | **К-3** |
| Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре, урыннар | 455 | 169 | 139 |
| Гомуми белем бирү учреждениеләре, урыннар | 962 | 357 | 293 |
| Тренажер залы, бассейны булган физкультура-сәламәтләндерү комплексы, идәннең гомуми мәйданы кв.м/ су өслеге кв.м | 1062/113 | 394/42 | - |
| Автотранспортны даими саклау өчен, машина/урын | 1349 | 626 | 411 |
| Автотранспортны вакытлыча саклау өчен (килүчеләр өчен), машина/урын | 226 | 112 | 69 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Эченә кертеп төзелгән, кушып төзелгән һәм эченә кертеп-кушып төзелгән биналар, машина/урын | 119 | 83 | 27 |

*- парковка урыннары саны балалар поликлиникасы өчен урыннарны исәпкә алып күрсәтелгән.

Искәрмә. Күрсәткечләр (фатирлар мәйданы, коммерция биналары мәйданы, якында урнашкан объектларны нигезләү) кимегән очракта парковка урыннарына һәм башка объектларга ихтыяҗ проектлауның алдагы стадияләрендә яңадан исәпләнә».

1.4. 1.3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.3 таблица

**Күпкатлы торак төзелешен план буенча урнаштыру зонасы объектлары характеристикалары**

| **Капиталь төзелеш объектлары характеристикалары** | **Планлаштыру структурасы элементы (квартал) чикләрендә билгеләнеше** | |
|---|---|---|
| | **К-1** | **К-2** |
| Фатирларның гомуми мәйданы, кв.м | 126480 | 62500 |
| Торак булмаган билгеләнештәге эченә кертеп төзелгән, өстәп төзелгән һәм эченә кертеп-өстәп төзелгән биналарның гомуми мәйданы*, кв.м | 7400 | 5520 |
| Торак йортлар катларының максималь саны, җир өстендәге катлар саны | 28 | 24 |
| Планлаштырылган халык саны, кеше | 5622 | 2084» |

3.9. 2 таблицаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2 таблица

**Кварталлар составында төзелеш**

| **Квартал билгеләнеше** | **Капиталь төзелеш объектлары*** | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | **Күпкатлы торак төзелеше** | **Мәктәпкәчә, башлангыч һәм урта гомуми белем бирү** | **Коммуналь инфраструктура** | **Автотранспортны саклау** | **Иҗтимагый билгеләнештә** |
| **Билгеләнеше** | | | | | |
| К-1 | Күпфатирлы йорт, Ф | - | I, II | - | - |
| К-2 | Күпфатирлы йорт, Ф, ПЛК | Д-1 | - | - | - |
| К-3 | - | Д-2, Д-3, Ш-1 | I, II, III | П-4, П-5 | А |
| К-4 | - | - | I, II, III | П-1, П-2, ОП | - |
| К-5 | - | - | II | П-3 | - |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| К-6 | - | - | I, IV | - | - |

*планлаштырыла торган объектларның эшләве һәм гражданнарның тормыш эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка объектлар проектлауның алдагы стадияләрендә төгәлләштерелә.

Экспликация:

Күпфатирлы йортлар – эчендә төзелгән, кушып төзелгән һәм/яки эчендә төзелгән-кушып төзелгән биналары булган күпфатирлы торак йортлар;

Ф – тренажер залы, бассейны булган физкультура-сәламәтләндерү комплексы (кертеп төзелгән яисә кушып төзелгән һәм/яисә кертеп-кушып төзелгән);

Д – мәктәпкәчә белем бирү оешмасы;

Ш – гомуми белем бирү оешмасы;

А – иҗтимагый билгеләнештәге объектлар (объект составында банк бүлекчәсе, торак-эксплуатация оешмасы, хокук тәртибен саклау пункты) ;

П – күпкатлы паркинг;

ОП – ачык парковка;

ПЛК – сәламәтлек саклау объекты (балалар поликлиникасының сменага 60-80 кеше кабул итүгә исәпләнгән филиалы, кертеп төзелгән яки кушып төзелгән һәм/яки кертеп-кушып төзелгән);

I – агып төшкән яңгыр суларын локаль чистарту корылмалары;

II – трансформаторлы подстанция, РТП;

III – котельный;

IV – канализация-насос станциясе»;

1.6. 2.1 «Чик параметрлар» пунктында:

1.6.1. икенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«К-1, К-2, К-3, К-4 кварталларында урнашкан җир кишәрлекләре өчен капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре сызымында чагылыш тапкан төзелешне җайга салу линияләре нигезендә җир кишәрлекләре чикләреннән калдыру өчен минималь аралар билгеләнә. Төзелешне җайга салу линияләре булмаган очракта, К-1, К-2, К-3, К-4 (бары тик П-1, П-2) өчен җир кишәрлекләре чикләреннән минималь ара 2.1 таблицасы нигезендә билгеләнә»;

1.6.2. 2.1 таблицаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.1 таблица

**Җир кишәрлекләре өчен капиталь төзелеш объектларын төзүнең рөхсәт ителгән чик параметрлары**

| Квартал билгеләнеше | Коды | Рөхсәт ителгән файдалану төре аталышы | Объектлар | Чик параметрлар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Җир кишәрлеге чикләреннән калдырылган буш ара (м) | | | Төзелеш проценты (%) | Төзелеш тыгызлыгы (торак фонды) (мең кв.м/га) | Яшелләндерү проценты (%) |
| | | | | П | Б | З | | | |
| К-1 | 2.6 | Стилобатлы күпкатлы торак төзелеше (бик биек биналар) | Барлык төр объектлар | 0 | 0 | 0 | 90 | 28,5 | 18,0 |
| К-2 | 2.6 | Стилобатлы күпкатлы торак төзелеше (бик биек биналар) | | 0 | 0 | 0 | 65 | 25,72 | 14,0 |
| К-4,К-3 | 2.7.1 | Автотранспортны саклау | | 0 | 0 | 0 | 80 | - | - |

Искәрмә. К-5, К-6 кварталлары, К-4 кварталының бер өлеше өчен (автотранспортны саклаудан тыш) җир кишәрлекләре өчен капиталь төзелеш объектларын төзүнең рөхсәт ителгән чик параметрлары Казан шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә билгеләнә»;

1.7. 2.2«Социаль инфраструктура объектларының һәм башка билгеләнештәге объектларның характеристикалары» пунктында:

1.7.1. 2.2 таблицаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.2 таблица

**Күпкатлы торак төзелеше объектлары характеристикалары**

| Исеме | Егәрлеге |
|---|---|
| **Социаль объектлар** | |
| Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы (Д-1) | 330 урын |
| Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы (Д-2) | 330 урын |
| Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы (Д-3) | 120 урын |
| Гомуми белем бирү оешмасы (Ш-1) | 1501 урын |
| **Хезмәт күрсәтү объектлары** | |
| Банк бүлекчәсе, торак-эксплуатация оешмасы, хокук тәртибен саклау пункты | Иҗтимагый билгеләнештәге зона объекты составында |

| | |
|---|---|
| Кертеп төзелгән, кушып төзелгән һәм/яисә кертеп-кушып төзелгән биналардагы объектлар, шул исәптән:<br>- тренажер залы, бассейны булган физкультура-сәламәтләндерү комплекслары (Ф) – 2 объект;<br>- балалар поликлиникасы филиалы | идән буенча 2 932 кв.м;<br>бер сменага 60-80 кеше/800 кв.м» |

1.7.2. 2.2 таблицадан соңгы беренче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«К-2 кварталы өчен 2.2 таблицада күрсәтелгән белем бирү оешмалары арасында Д-1 мәктәпкәчә белем бирү оешмасында 185 урын һәм Ш-1 гомуми белем бирү оешмасында 243 урын каралган».

2. Территорияне план буенча үстерү чираты турында нигезләмәдә:

2.1. 2 «Территорияне план буенча үстерү этаплары» пунктында 1 таблицаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1 таблица

**Техник-икътисади күрсәткечләр**

| **Күпкатлы торак төзелеше объектлары характеристикалары** | **Планлаштыру структурасы (микрорайон) элементы билгеләнеше** | | **Барлыгы** |
|---|---|---|---|
| | **К-1** | **К-2** | |
| Фатирларның гомуми мәйданы, кв.м | 126480 | 62500 | 188980 |
| Торак булмаган билгеләнештәге эчкә кертеп-кушып төзелгән биналарның гомуми мәйданы, кв.м | 7400 | 5520 | 12920 |
| Күпкатлы торак йортларда планлаштырыла торган кеше саны, кеше | 5622 | 2084 | 7706» |

2.2. 3 «Объектларны төзү һәм реконструкцияләү этаплары» пунктында 1 таблицаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Таблица

| **Планлаштыру структурасы элементлары билгеләнеше** | | **I этап** | **Территорияне планлаштыру проектын гамәлгә ашыруның исәпләнгән вакыты** |
|---|---|---|---|
| | | **Объектларның әһәмияте** | |
| М-1 | К-1* | Күпфатирлы йорт, Ф, О-1 | - |
| | К-5 | Күпфатирлы йорт, Ф, О-2, ПЛК | Д-1 |
| | К-4 | П-1, П-2, ОП, Ш | - |
| | К-5 | П-3 | - |
| | К-6 | О-4, О-6 | - |
| | М-1 | 2, 3, 4, 6 юллар | - |
| М-2 | К-3 | П-4, Ш | Д-2, Д-3, Ш-1, О-3, П-5, А |
| | М-2 | 1 юл | - |

| | | |
|---|---|---|
| Район | Килүчеләр өчен парковка урыннары | Журналистлар урамы, Халитов урамы өлешләрен реконструкцияләү |

* К-1 кварталында соңгы торак йортны файдалануга кертү П-1, П-2, П-4 паркингларын төзү, О-1 гомуми файдаланудагы яшелләндерү территориясен төзекләндерү, К-1 кварталын төзү өчен кирәкле санда парковка урыннарын оештыру тәмамлану белән бер үк вакытта мөмкин.

**К-2 кварталын үзләштерү төзелеш проекты (территориядә төзелеш алып баруның планлаштырылган һәм күләмле-пространстволы карары) килештерелгәннән соң мөмкин. К- 2 кварталында соңгы торак йортны файдалануга кертү П-3 паркингын төзеп бетерү, О-2, О-4, О-6 гомуми файдаланудагы яшелләндерү территорияләрен төзекләндерү һәм К-2 кварталын төзү өчен кирәкле санда парковка урыннарын оештыру белән бер үк вакытта мөмкин».